ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында:

а) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларын бозган өчен административ җаваплылык билгеләү»;

б) тугызынчы абзацта «(башкарма-күрсәтмә биру органы)» сүзләрен «(муниципаль берәмлекнең башкарма-күрсәтмә биру органы) (алга таба шулай ук – муниципаль берәмлекнең администрациясе)» сүзләренә алмаштырырга;

в) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекләрнең Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенцияләр исәбеннән үтәлергә тиешле чыгым йөкләмәләрен билгеләү һәм үтәү тәртибен билгеләү;»;

г) унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«федераль салымнардан һәм җыемнардан, шул исәптән махсус салым режимнары белән каралган салымнардан, һәм (яисә) Россия Федерациясе Бюджет кодексы, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле региональ салымнардан җирле бюджетларга керемнәр күчерү нормативларын билгеләү;»;

е) ундүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 6[1] статьяның 1[1] өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) гадәттән тыш хәлләр режимы гамәлдә булган чорга табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектларына.»;

3) 9 статьяда:

а) 8 өлешнең икенче абзацында «“Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында”» сүзләреннән соң «2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

б) 10 өлештә «коммерциягә карамаган оешмалар турында федераль закон» сүзләрен «“Коммерциягә карамаган оешмалар турында” Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

4) 20 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле яңа ундүртенче абзац өстәргә:

«инициатив проектлар;»;

ундүртенче абзацны унбишенче абзац дип санарга;

б) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Инициатив проектларны тәкъдим итү, кертү, алар турында фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс ярдәмендә сайлап алуны уздыру тәртибе муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы (вәкиллекле орган вәкаләтләрен башкара торган гражданнар җыены) тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән финанс ярдәме алу өчен тәкъдим ителә торган инициатив проектларга карата инициатив проектларда булырга тиешле белешмәләр составына таләпләр, инициатив проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларны хуплаудан баш тарту өчен нигезләр, мондый инициатив проектларны конкурс ярдәмендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә.»;

5) 49 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

6) 51 статьяның 1 өлешендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, дәүләт урындагы затлары, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт

вазыйфаларын биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы дәүләт органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеге**

1) Азнакай муниципаль районы;
2) Әлки муниципаль районы;
3) Әлмәт муниципаль районы;
4) Апас муниципаль районы;
5) Арча муниципаль районы;
6) Балтач муниципаль районы;
7) Бөгелмә муниципаль районы;
8) Буа муниципаль районы;
9) Югары Ослан муниципаль районы;
10) Биектау муниципаль районы;
11) Алабуга муниципаль районы;
12) Зәй муниципаль районы;
13) Зеленодольск муниципаль районы;
14) Кама Тамагы муниципаль районы;
15) Кукмара муниципаль районы;
16) Лаеш муниципаль районы;
17) Лениногорск муниципаль районы;
18) Менделеевск муниципаль районы;
19) Минзәлә муниципаль районы;
20) Мөслим муниципаль районы;
21) Түбән Кама муниципаль районы;
22) Яңа Чишмә муниципаль районы;
23) Питрәч муниципаль районы;
24) Балык Бистәсе муниципаль районы;
25) Саба муниципаль районы;
26) Тукай муниципаль районы;
27) Теләче муниципаль районы;

28) Чистай муниципаль районы;

29) Чаллы шәһәре.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 һәм 7 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 һәм 7 пунктлары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 26 декабрь
№ 95-ТРЗ